ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

**КАРАР**

**« 30 » сентябрь 2016 ел** **№34**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 60 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда да юлларны вак ташлау: | 439250,00 |
| | | Шушмабаш авылы | |
| | | Librariesтакташ ур. -200м | 14900,00 |
| | | Бакча ур. -500м | 37250,00 |
| | | Урак һәм Чүкеч ур. -1000м | 74500,00 |
| | | Шекә авылы | |
| | | Ворошилов ур. -500м | 37250,00 |
| | | Коммуна ур. -500м | 37250,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Носы авылы<br>Татарстан ур. -500м<br>Сәрдәбаш<br>Җиңүнең 65 еллыгы ур -1000м<br>М.Жуков ур -300м<br>Г.Тукай ур. -500м<br>Ильдус авылы<br>Н.Сафина ур-500м<br>Угез-Елга авылы<br>Яшел ур.-400м | <br>37250,00<br><br>74500,00<br>22350,00<br>37250,00<br><br>37250,00<br><br>29500,00 |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерү эшләрен оештыру | -кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту<br>Шушмабаш авылы<br>Шекә авылы<br>Носы авылы<br>Ишнарат авылы<br>- урам утлары (светодиод лампочкаларга алыштыру)<br>Шушмабаш 52шт.<br>Шека 21 шт.<br>Нуса 31 шт.<br>Сердебаш 23 шт.<br>Ишнарат 10шт<br>Ильдус 7 шт<br>Угез-Елга 6 шт.<br><br>Угез-Елга авылында яшел үсентеләрне санитар кисү-<br><br>Хишмәләр территориясен төзекләндерү<br>Шушмабаш авылында "Мәхамадулла" чишмәсе<br>Сәрдәбаш авылында "Үзәк" чишмә<br><br>Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда да каты коммуналь калдыкларны вакытлыча урнаштыру урыннарын карап тоту, җыю һәм чыгаруны оештыру. | <br><br>3332,00<br>2499,00<br>4169,00<br>2000,00<br><br><br>31200,00<br>12600,00<br>18600,00<br>13800,00<br>6000,00<br>4200,00<br>3600,00<br><br>20000,00<br><br><br><br><br>20000,00<br><br>15000,00<br><br><br>40000,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар булдыру. | -торак пунктларда балалар мәйданчыклары урнаштыру<br>Шушмабаш авылы Мәктәп ур.<br>Шекә авылы Свердлов ур.<br>Носы авылы Татарстан ур<br>Сәрдәбаш авылы Җиңүнең 65 еллыгы урамы | <br><br>20000,00<br>20000,00<br>20000,00<br>20000,00 |
| | | | 716250 |

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә

Әйе                                                    юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп ур., 1б йорт, Татарстан Республикасы, Арча районы, Носы авылы, Татарстан урамы, 45 йорт.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы                    В.В.Сәгыйтов